КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 март г.Казань № 280

Татарстан Республикасының фәнни-технологик һәм инновация үсеше нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 29 мартындагы 377 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасының фәнни-технологик һәм инновацион үсеше нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасының фәнни-технологик һәм инновацион үсеше өлкәсендә проект офисы (алга таба – Проект офисы) вәкаләтләрен бирү турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставын раслау һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасының Попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 11 февраль, 83 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 10 август, 550 нче; 2016 ел, 23 август, 586 нчы; 2017 ел, 24 апрель, 243 нче; 2018 ел, 27 март, 177 нче; 2019 ел, 3 август, 640 нчы; 2020 ел, 3 июнь, 462 нче; 2020 ел, 8 октябрь, 913 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставына, 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.1. Фонд эшчәнлегенең максаты – Татарстан Республикасының фәнни-технологик һәм инновацион потенциалын арттыру, Татарстан Республикасында социаль-мәдәни өлкәне һәм иҗтимагый инфраструктураны яхшырту. Фонд эшчәнлегенең предметы:

Татарстан Республикасының инновацион һәм фәнни-технологик үсеше өлкәләрендә дәүләт идарәсе системасының стратегик, концептуаль, программа һәм инструменталь нигезләре буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасының инновацион һәм фәнни-технологик үсеше өлкәләрендә бурычларны тормышка ашыру процессларына мәгълүмати-методик, оештыру-технологик һәм финанс-икътисадый булышлык күрсәтеп тору;

фән казанышларына нигезләнгән җитештерүләрне үстерү һәм яңа прогрессив технологияләрне кертү;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасының сәнәгый үсеше буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына законнарга туры килә торган теләсә нинди формада финанс һәм башка ярдәм күрсәтү аша катнашу;

Татарстан Республикасында социаль инвестицияләрдә һәм социаль юнәлешле инвестиция проектларында катнашу;

Татарстан Республикасында социаль программаларны тормышка ашыруда катнашу.».

3. «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе белән берлектә, 30 көн эчендә Проект офисында катнашучыларның оештыру-технологик һәм мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе белән берлектә, 30 көн эчендә «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасының, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең оештыру структурасын үзгәртү буенча тәкъдимнәр әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы белән берлектә, 30 көн эчендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмалары белән Татарстан Республикасының фәнни-технологик һәм инновацион үсеше өлкәсендә интеграция процессларын үстерү нигезендә хезмәттәшлек итү турында Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгы белән килешү проектын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, 30 көн эчендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы белән берлектә, «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасы проектын аның максатчан күрсәткечләренең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 29 мартындагы 377 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасының максатчан күрсәткечләре белән үзара бәйләнешен исәпкә алып эшләүне һәм 2022 елның июненә кадәрге срокта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин